ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

28 апрель 2018 ел

№ 2398

Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5950 нче карары белән расланган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5950 нче карары белән (2016 елның 27 июнендәге 3269 нчы, 2017 елның 30 гыйнварындагы 394 нче, 2017 елның 29 сентябрендәге 5872 нче карарлары редакциясендә) расланган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3.1 пунктның 12 абзацындагы «38-21-83» цифрларын «47-55-72» цифрларына алмаштырырга;

2) 1.4 пунктның алтынчы абзацын төшереп калдырырга;

3) 1.4 пунктның җиденче абзацындагы «2015-2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Гражданнарның федераль законнар белән билгеләнгән категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» ярдәмче программасын тормышка ашыруның аерым мәсьәләләре турында» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Гражданнарның федераль законнар белән билгеләнгән категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт

йөкләмәләрен үтәү» топ чарасын тормышка ашыруның аерым мәсьәләләре турында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 2.5 пунктның икенче баганасында:

- 5 пунктчаның икенче абзацындагы «дәвалау медицина учреждениесе» сүзләрен «медицина оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

- 5 пунктчаның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

5) 2.8 пунктның икенче баганасындагы 2 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

6) 2.9 пунктның икенче баганасын түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктча белән тулыландырырга:

«4) вәкаләтле орган запросы буенча алынырга мөмкин булган документлардан тыш, ТР 31-ТРЗ санлы Законының 6 маддәсендә каралган документларны тапшырмау»;

7) 5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгечләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе»;

8) 5.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә Башкарма комитетка, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк белгечләре буенча – күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне оештыручыга шикаять бирергә хокуклы.»;

9) 5.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының законнарында һәм башка хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату.»;

10) 5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә яки электрон төрдә бирелә.

Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.»;

11) 5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгеченең гариза

бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.»;

12) 5.4 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) карарларыннан һәм эш итүләреннән (эш итмәүләреннән) риза булмыйча шикаять бирелә торган Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгеченең исеме;»;

13) 5.4 пунктның 3 һәм 4 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгеченең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүматлар;

4) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгеченең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән гариза бирүченең килешмәвен нигезләүче дәлилләр.»;

14) 5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокуый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.»;

15) 5.9 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.»;

16) 5.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.10. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгечләренең карарларыннан, эш итүләреннән (эш итмәүләреннән) риза булмыйча, Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.»;

17) кушымтаны (беленмә) кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 28 апрелендәге
2398 нче карарына
кушымта

Кушымта (белешмә)

Башкарма комитет районнары Хакимиятләренең
муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларының
реквизитлары

| Т/с | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Комсомол районы | | | |
| 1. | Хакимият Башлыгы | 70-34-27 | ikkr@mail.ru |
| 2. | Халык белән эшләү бүлекчәсе мөдире | 70-45-46 | ikkr@mail.ru |
| 3. | Әйдәүче белгеч | 70-04-32 | ikkr@mail.ru |
| Үзәк районы | | | |
| 1. | Хакимият Башлыгы | 47-55-33 | ispolkom_cr-nch@mail.ru |
| 2. | Халык белән эшләү бүлекчәсе мөдире | 47-55-72 | ispolkom_cr-nch@mail.ru |
| 3. | Әйдәүче белгеч | 47-55-73 | ispolkom_cr-nch@mail.ru |
| Автозавод районы | | | |
| 1. | Хакимият Башлыгы | 56-50-71 | avtoispolcom@mail.ru |
| 2. | Халык белән эшләү бүлекчәсе мөдире | 32-98-39 | avtoispolcom@mail.ru |
| 3. | Әйдәүче белгеч | 56-74-16 | avtoispolcom@mail.ru |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова